# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
**Чираттан тыш утырыш**

**01 ноябрь 2024 ел** **№ 228** **Үзәк п.**

**Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге № 186 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым Кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 7 октябрендәге 10/13-09/4537 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советы хәл итте:

1. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге № 186 номерлы "Җир салымы турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм җир кишәрлекләре, аларның һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;»;

Б) 2 пунктның Б пунктчасы үз көчен югалткан дип таныйрга.

в) В, Г пунктчаларын Б, В пунктчалары дип санарга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2 пунктның А пунктчасыннан тыш, гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Үзәк авыл җирлеге башлыгы: В.Н. Котников